**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**07.10.2019** **№1707**

# Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентны раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге Федераль законны тормышка ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтү административ регламентын эшләп чыгару һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”, 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Карары белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентны расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф.Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты карары белән
07.10.2019 N 1707

**Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү**
**Админстратив регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты (алга таба - Регламент) бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Хезмәтне алучылар: юридик һәм физик затлар – торак биналарның милек ияләре (арендага алучылар).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның төзелеш, ТКХ, элемтә һәм энергетика буенча бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашкан урыны – Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 йорт.

Бүлекнең урнашкан урыны: Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Кооперативная урамы, 5 йорт.

Эш графигы:

дүшәмбе - пәнҗешәмбе: 8.00 дән 17.00гә кадәр;

җомга: 8.00 дән 17.00гә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнелә.

Белешмәләр өчен телефон 8(84365)2-30-68.

Керү шәхесне раслаучы документлар белән.

1.3.2. Муниципаль районның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты адресы: (www.visokaya-gora_.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт, шулай ук Бүлекнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет биналарында урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүмат туплаган мәгълүмат стендлары аша;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларда (пунктчаларда) күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә ала.

2) "Интернет" челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (www.visokaya-gora_.tatar.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

- телдән мөрәҗәгать иткәндә-шәхсән яки телефон буенча; - язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет биналарында мәгълүмати стендларда урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәгеләргә туры китереп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – РФ Торак кодексы) (РФ Законнары җыелмасы, 03.01.2005, №1 (1 кисәк), 14 ст);

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2003 елның 6 октябрендәге 40нчы номерлы 3822 ст.);

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында", 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыелмасының 2010 елның 2 августындагы 31нче номерлы 4179 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау турында", 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (алга таба – Нигезләмә) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 06.02.2006, № 6, 702 ст.);

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында", 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (Республика Татарстан, 2004 елның 3 августындагы 155-156 номерлары);

Биектау муниципаль районы Советының 2014 елның 21 сентябрендәге 7 номерлы карары белән расланган, Биектау муниципаль районы Советының 28.09.2016 № 86, 29.11.2016 № 110, 26.09.2017 № 145, 28.03.2018 N 205 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 16 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты" МКУ турында нигезләмә (алга таба – Башкарма комитет турында Нигезләмә);

"Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында", 2010 елның 30 декабрендәге 3338 номерлы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

торак бина – гражданнар яшәү өчен билгеләнгән күчемсез милек булып торган һәм яшәү өчен яраклы изоляцияләнгән бина;

торак бина дип таныла:

торак йорт – бүлмәләрдән, шулай ук гражданнарның анда яшәве белән бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмчел куллану биналарыннан торган шәхси-билгеләнгән бина;

фатир – бер яки берничә бүлмәдән торган, мондый йортта уртак файдалану урыннарына турыдан-туры керү мөмкинлеген тәэмин итә торган, шулай ук гражданнарның үзенә аерым урында яшәве белән бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмчел куллану биналарыннан торган күпфатирлы йортта структур аерымланган бина;

бүлмә – гражданнарның торак йорт яки фатирда турыдан-туры яшәү урыны сыйфатында файдалану өчен билгеләнгән торак йортның яисә фатирның бер өлеше;

күпфатирлы йорт – торак йорт янындагы җир кишәрлегенә яисә мондый йорттагы гомуми файдалану урыннарына мөстәкыйль чыгу урыны булган ике һәм аннан күбрәк фатир җыелмасы. Торак законнары нигезендә, күпфатирлы йорт мондый йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми милке элементларын үз эченә ала;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яки авыл җирлекләрендә оештырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең эшчәнелеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында", 2012 елның 22 декаберендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең эшчәнелеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә,территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуныңише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) астында муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы сорату аңлашыла (27.07.2010, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 2 пункты). Гариза стандарт бланкта (1 нче кушымта) тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандарт таләпләренең эчтәлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү яисә таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану | РФ ТКның 14 ст. 1 б. 8 пп |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-оештыручы органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты | Башкарма комитет турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | Торак бинаны яшәү өчен яраклы түгел (яраклы) дип тану турында карар.<br>Әгәр дә торак бинаны яшәү өчен яраклы түгел дип тапкан очракта - йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле яки төзекләндерү-булдыру эшләрен уздыру кирәк дип табылган очракта, бинаны алга таба да куллану, физик һәм юридик затларны күчерү сроклары күрсәтеп Карар | Нигезләмәнең 49 пункты |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә | Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы –гариза бирү көнен дә кертеп, 30 календарь көн һәм карар каблу игелә (бәяләмә рәвешендә), яисә бәяләнә торган бинаны карап тикшерү уздыру турында карар. | |

| | | |
|---|---|---|
| алып, туктатылу мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Комиссиянең чираттагы утырышын көтү срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны күрсәтү тәртибе | 1) Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм (яки) күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында гариза;<br>2) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән торак бинага хокук билгеләүче документларның күчермәләре;<br>3) Торак булмаган бинага карата аны киләчәктә торак бина дип тану өчен – торак булмаган бинаны реконструкцияләү проекты.<br>4) Күпфатирлы йортны тикшерүне үткәргән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе – күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турындагы мәсьәлә куелганда;<br>5) Торак бинаның киртәләү һәм корылма конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча проекттикшеренү оешмасы нәтиҗәсе – әгәр мондый нәтиҗә бирү билгеле Нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килә (килми) дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк булганда.<br>Гариза бирүченең теләге буенча шулай ук гариза, хатлар, гражданнарның канәгатьләнерлек булмаган яшәү шартлары турында шикаятьләре тәкъдим ителергә мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган. | Нигезләмәнең 45 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм теркәлгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эшләүче зат);<br>почта аша җибәрү.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында барлыкка килә:<br>1) торак бинага хокук турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан мәгълүматлар;<br>2) торак бинаның техник паспорты, ә торак булмаган биналар өчен – техник план;<br>3) күрсәтелгән документларны тапшыру торак урынны Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә (килми) дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк дип танылган очракта, дәүләт күзәтчелеге (контроль) тиешле органнарының нәтиҗәсе (актлары).<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган | Нигезләмәнең 45 (2) пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүчедән югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган, аларны килештерү очраклары норматив хокукый актлар белән каралган дәүләт хакимияте (җирле үзидарә органнары) органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документларны тиешле булмаган зат тарафыннан тапшыру;<br>2) Тәкъдим ителгән документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;<br>3) Гаризада һәм гаризага беркетелгән документларда аларның эчтәлеген ачыктан-ачык аңларга мөмкинлек бирми торган алдан әйтелмәгән төзүтүләр, җитди хилафлыклар бар;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тәкъдим итү. | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) Гариза бирүче тарафыннан документлар тулы күләмдә түгел, я тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;<br>2) Әгәр тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз | Нигезләмәнең 33-40 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | инициативасы буенча тапшырылмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында таныклаучы ведомствоара соратуга дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы оешмасының ведомство карамагындагы органына җавап килү;<br>3) Торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен нигезләр булмау. | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган дәүләт пошлинасы яисә башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан да артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алган очракта чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуын, шул | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән сорату ял | |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән электрон формада да теркәү вакыты | (бәйрәм) көне артыннан килгән эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге күләме һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә муниципаль хезмәт алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарында, | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>гариза кабул итү һәм документлар пакеты алу бинасының җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтүе алучы инвалидларга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгарга ярдәм | |

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланып | күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булуы.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе алганда – муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге. Хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮнең ераклаштырылган эш урыннарында консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Биектау муниципаль районы сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында һәм КФҮдә алынырга мөмкин | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада тәкъдим итү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтләрне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша | |

| | | |
|---|---|---|
| | алырга мөмкин.<br>Гариза электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы (http://uslugi.tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы (http:/ www.gosuslugi.ru/) аша бирелә.<br>Электрон документ формасында тәкъдим ителә торган гариза гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза белән имзалана, ә аңа беркетелә торган электрон документлар, әлеге документларны биргән органнарның (оешмаларның) вазыйфаи затлары тарафыннан көчәйтелгән электрон имза белән имзаланырга тиеш (әгәр дә әлеге документларга имза куяр өчен Россия Федерациясе законнары белән башка төр электрон имза төре билгеләнмәгән булса). | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, күпфункцияле үзәгенең ераклаштырылган эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр тәртибен тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү;

4) урында бинаны карау һәм актны рәсмиләштерү;

5 муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

3.2.1. Гариза бирүче Бүлеккә шәхсән үзе, телефон буенча һәм (яки) электрон почта аша, муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документлар составы, формасы һәм башка сораулар буенча һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә кирәкле документлар составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка сораулары буенча консультация.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, яисә ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5. пункты нигезендә документларны КФҮ, КФҮнең еракта урнашкан эш урыны аша Бүлеккә тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза электрон формада Бүлеккә электрон почта, Интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада килгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризаларны кабул итүче Бүлек белгече тормышка ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышаныч кәгазе буенча гамәл кылганда);

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күздә тотылган документларның булуын тикшерә;

тәкъдим ителгән документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә (документларның күчермәләре тиешенчә рәсмиләштерелүе, сызылган сүзләр һәм башка сөйләшенмәгән төзүтүләр булмавы).

Искәрмәләр булмаган очракта Бүлек белгече тормышка ашыра:

гаризаны кабул итү һәм махсус журналда теркәү;

гариза бирүчегә тәкъдим ителгән документларның күчермәләрен документларны

кабул итү датасын, бирелгән керү номерын, муниципаль хезмәт башкару датасы һәм вакыты турында тамга белән бирү;

гаризаны каралу өчен Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, документларны кабул итүче Бүлек белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар тормышка ашырылалар:

гаризаны һәм документларны кабул итү 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү гариза кергән вакыттан бер көн дәвамында.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә каралу өчен җибәрелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм гаризаны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура, гариза теркәлгән вакыттан бер көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара соратулар формалаштыру һәм җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша тәкъдим итү турында соратулар җибәрә:

1) торак бинага хокук турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан мәгълүматлар;

2) торак бинаның техник паспорты, ә торак булмаган биналар өчен – техник план;

3) торак урынны Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килә (килми) дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк дип танылган очракта, дәүләт күзәтчелеге (контроль) тиешле органнарының бәяләмәсе (актлары).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән соратулар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән сорату нигезендә, мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр соратып алына торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавы турында хәбәрнамә җибәрәләр (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә).

Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (белешмәләр) буенча өч эш көненнән дә артмаска тиеш;

башка тәэмин итүчеләр буенча – документ яисә мәгълүмат бирүче органга яки оешмаларга ведомствоара соратулар кергән көннән алып биш көн эчендә, әгәр ведомствоара соратуга җавап әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар

нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5. Бинаны урында карауны уздыру һәм актны рәсмиләштерү

3.5.1. Бүлек белгече гаризаны карый, әлеге Регламентның 2.9. пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуны тикшерүне гамәлгә ашыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булмаган очракта Бүлек белгече гамәлгә ашыра:

документларны туплау (дело формалаштыру);

документларны муниципаль торак фондының торак биналарга бәя бирү ведомствоара комиссиясенә (алга таба - Комиссия) җибәрә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече тормышка ашыра:

муниципаль хезмәтне күрсәтүдән баш тарту турында бәяләмә әзерләү;

документларны туплау (дело формалаштыру);

документларны комиссиягә җибәрү;

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар соратуларга җаваплар алганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссиягә җибәрелгән документлар.

3.5.2. Комиссия сәркатибе тормышка ашыра:

кергән документларны өйрәнү;

комиссия утырышы көнен билгеләү;

комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр җиткерү.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар документлар кергәннә соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына комиссия утырышы көне турында хәбәр җиткерү.

3.5.3. Комиссия сәркатибе бинаны карау өчен җәлеп ителә торган экспертлар составын ачыклый һәм карау датасын билгели. Карау датасы турында хәбәр комиссия әгъзалары, гариза бирүчеләр һәм экспертлар җибәрелә.

Әлеге пунктча тарафыннан тормышка ашырыла торган процедура бинаны карау уздыру турында комиссия карары чыгарылган вакыттан ике көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына, гариза бирүчегә карау датасы турында хәбәр җибәрү.

3.5.4. Билгеләнгән көндә комиссия урынга чыга һәм экспертлар һәм гариза бирүче катнашында бинаны тикшерүне уздыра. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бинаны тикшерү акты төзелә.

Әлеге пунктча тарафыннан тормышка ашырыла торган процедуралар бинаны карау көнендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бинаны тикшерү акты.

3.5.5. Комиссия сәркатибе бинаны карау актын комиссия каралуына әлеге Регламентның 3.5 пункты белән билгеләнгән тәртиптә кертә.

Әлеге пунктча тарафыннан билгеләнелә торган процедура, бинаны тикшерү уздыру вакытыннан ике көн дәвамында тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия  каралуына  кертелгән бинаны тикшерү акты.

3.5.6. Комиссия үз утырышында:

торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турындагы гаризаны карый;

бинаның Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү үткәрә;

әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булу турындагы нәтиҗәне тикшерә;

бинаны урында карау һәм бинаны тикшерү актын рәсмиләштерү кирәклеген билгели.

Бинаны карап тикшерү кирәк булмаган очракта, комиссия торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында карар кабул итә. Карар беркетмәгә кертелә.

Бинаны урында карап тикшерү һәм бинаны тикшерү актын рәсмиләштерү кирәк булган очракта, комиссия әгъзалары әлеге Регламентның 3.5.3-3.5.4 пунктчаларында каралган процедураларны гамәлгә ашыралар. Торак бинаны яшәргә яраклы (яраксыз) дип тану мөмкинлеге турындагы карар актны рәсмиләштергәннән соң кабул ителә.

Әлеге пунктча белән билгеләнә торган процедура, киңәшмә утырышы көнне тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында карар.

3.5.7. Комиссия сәркатибе комиссия карарын бәяләмә формасында рәсмиләштерә (3 нөсхә) һәм комиссия әгъзаларына имзалауга тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: имза куюга тапшырылган бәяләмә.

3.5.8. Комиссия әгъзалары бәяләмәне имзалыйлар һәм сәркатибкә юллыйлар.

Әлеге Регламентның 3.5.6-3.5.7 пунктчалары белән билгеләнә торган процедуралар карар чыгарылганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары кул куйган бәяләмә.

3.5.9. Бүлек белгече имзаланган бәяләмәне комиссия рәисенә раслауга җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: раслауга юнәлдерелгән бәяләмә.

3.5.10. Комиссия рәисе бәяләмәне раслый һәм сәркатибкә тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган бәяләмә.

3.5.11. Комиссия сәркатибе расланган бәяләмәне гариза бирүчегә һәм торак бина милекчесенә (берәр нөсхә) тапшыра. Бер нөсхә комиссия формалаштырган делода кала, ул Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге Регламентның 3.5.9-3.5.11 пунктчалары белән билгеләнә торган процедуралар 3.5.8 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә, гариза бирүчегә, бина милекчесенә җибәрелгән расланган бәяләмә.

3.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен әзерләү.

3.6.1. Бүлек белгече бәяләмә нигезендә:

торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында Башкарма комитет карар проектын әзерли. Карар проектында торак бинаны яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта, бинаны алга таба да куллану, физик һәм юридик затларны күчерү сроклары  күрсәтелә;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедурасын гамәлгә ашыра;

документ проектын Башкарма комитет җитәкчесенә (аның вәкаләтле затына) имзалауга җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура бәяләмә кергән вакыттан алып ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет җитәкчесенә имзалауга юнәлдерелгән карар проекты.

3.6.2. Башкарма комитет җитәкчесе карарга кул куя һәм Бүлеккә теркәү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проектлар кергәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлү өчен җибәрелгән имзаланган карар.

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Бүлек белгече гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм гариза бирүчегә карарны бирә яисә почта аша җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

15 минут эчендә – гариза бирүченең шәхси килүе очрагында;

алдагы процедуралар тәмамланганнан соң бер көн эчендә почта аша җавап җибәрелгән очракта

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән яки почта аша җибәрелгән карар.

3.8. Муниципаль хезмәтне КФҮ тарафыннан тәкъдим итү

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәтне алу өчен КФҮ, КФҮнең еракта урнашкан эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.8.2. Муниципаль хезмәтне КФҮ аркылы тәкъдим итү КФҮ эшенең регламенты нигезендә, билгеләнгән тәртиптә расланган рәвештә тормышка ашырыла.

3.8.3. Муниципаль хезмәт алуга документлар КФҮтән килгән вакытта, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.6 пунктлары нигезендә тормышка ашырыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе КФҮкә җибәрелә.

3.9. Техник хаталарны төзәтү.

3.9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак документта техник хаталар ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында гариза (4-нче кушымта);

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хата булган документ;

техник хаталар булуныраслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хаталарны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша бирелә.

3.9.2. Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хаталарны төзәтү турында гариза кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карауга юнәлдерелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.9.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, әлеге Регламентның 3.6. пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның оригиналын гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) төзәтелгән документны имзалатып шәхсән бирә, яки мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта аша) Бүлеккә техник хата булган документның төп нөсхәсен тапшырганда, документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хаталар ачыклангannнан яки теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерү, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган эшләр башкаруын тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерү үткәрү.

Контроль тикшерүләр план нигезендә (җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ярты еллык яки еллык планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда муниципаль хезмәт күрсәтү (комплексны тикшерүләр) белән бәйле барлык мәсьәләләр дә карала ала, яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру һәм карар кабул итү өчен Башкарма комитет җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләр үтәлешенә агымдагы контроль муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыру буенча җаваплы инфраструктур үсеш буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, шулай ук инфраструктур үсеш буенча Бүлек белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турында

нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгәне өчен җаваплылык тота.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яки) тиешенчә башкарылмавы өчен җаваплылык йөртә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аркылы тормышка ашырыла.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) гариза бирүченең судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Шикаять язмача формада кәгазьдә, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, яисә гавами-хокукый оештырылган, күп функцияле үзәкнең учредитле булган дәүләт хакимияте органының (алга таба – күп функцияле үзәкнең учредитле) билгеле органына (җирле үзидарә органы), шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларга тапшырыла. Дәүләт хезмәтен, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять өстә торучы органга бирелә (булган очракта) яисә ул булмаган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан турыдан-туры карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять, әлеге күп функцияле үзәкнең җитәкчесенә бирелә. Күп функцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять күп функцияле үзәкнең учредителенә яки Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка бирелә. “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә күздә тотылган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять әлеге оешмаларның җитәкчеләренә бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән шул исәптән түбәндәге очракларда да мөрәҗәгать итә ала:

1) “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән сорату, дәүләт яки муниципаль хезмәтне күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу.

2) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату теркәүнең срогын бозу. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү  эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

3) гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерацисе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында  каралмаган өстәмә документлар  яки мәгълүмат яисә эшчәнлек таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда  күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, федераль законнар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү  эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә билгеле дәүләт яки муниципаль хезмәтне тулы итеп “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 нчы статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта гына мөмкин.

6) гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткән очракта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъекты норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында  каралмаган түләү таләп итү;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче  органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче  органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә  күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына)

шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында монның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

10) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта кирәкле булган документларны кире какканда аларның юклыгы һәм (яки) тулы булмаганлыгы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматларны таләп итү, яисә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

5.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органга, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә төбәк дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре аркылы, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яисә төбәк дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә

кабул ителергә мөмкин. “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар һәм шулай ук аларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү почта, КФҮ, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре аркылы, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http:// www.visokaya-gora.tatar.ru.), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://www.gosuslugi.ru/) иясә төбәк дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүче, муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күп функцияле үзәк, күп функцияле үзәк учредителенә, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларга, яисә югары органга (булган очракта) кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күп функцияле үзәкнең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документлар кабул итүдән баш тартуы яисә җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтүдә яисә төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу турында шикаять бирү очрагында, теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күп функцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә – физик затның яисә исеме, гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелүче дәүләт хезмәте күрсәтү орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яисә муниципаль хезмәт

күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, күп функцияле үзәкнең, күп функцияле үзәк хезмәткәренең, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) белән килешмәве нигезендә торган дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең дәлилләрен раслый торган документлар (алар булган очракта), яисә аларның күчермәләре тәкъдим ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар һәм аларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Әлеге очракта шикаятьтә аңа беркетелгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тәкъдим иткән муниципаль хезмәтне алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча, түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, ләкин акча алу Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә каралмаган;

2) шикаять канәгатьләндерелүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көннән үк соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре күрсәтелгән дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта гариза бирүчегә җибәрелә торган җавапта муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында ачыкланган кагыйдә бозулар кичекмәстән юкка чыгару өчен дәүләт хезмәте күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчедән китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм киләчәктә муниципаль хезмәт алу максатларында гариза бирүче эшләргә тиешле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләрен аңлатып нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарны шикаять итү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Карарны кабул итү барышында яки шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрелә.

1 нче кушымта
Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентына

Муниципаль торак фонды
торак биналарына бәя бирү
Ведомствоара комиссиягә
__________________________________,
адресы буенча яшәүче:
______________________________________

**Бинаның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү үткәрү һәм торак бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында**
**ГАРИЗА**

Мин, ____________________, _______________________________________булам

(милекчесе, яллаучысы)

______________________________ адресы буенча урнашкан торак бинаның,

________________________________________________________белән раслана.

(милек хокукы турында таныклык, найм килешүе)
Әлеге торак бинаның милекчесе булып тора _____________________ нигезендә __________________ (әгәр гариза найм бирүче исеменнән бирелсә).

Әлеге торак бинаның “Бинаны торак урын, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәне раслау хакында”, 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы РФ Хөкүмәте Карары белән каралган таләпләргә туры килүен бәяләүне һәм торак бинаны, түбәндәге нигезләргә бәйле рәвештә, яшәү өчен яраклы (яраксыз), авария хәлендә дип тануны сорыйм:

____________________________________________________________

______________________________________________________________________

_____________________________________________________________________.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның Бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак бинага хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

2) торак булмаган бинага карата аны киләчәктә торак бина дип тану өчен – торак булмаган бинаны реконструкцияләү проекты;

3) күпфатирлы йортны тикшерүне үткәргән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе – күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турындагы мәсьәлә куелганда;

4) торак бинаны Нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килә (килми) дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк булган очракта, киртәләүче һәм торак конструкцияләренең элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча проект-тикшеренү оешмасы бәяләмәсе.

Сорату булганда, сканерланган документларның төп нөсхәләрен бирергә йөкләмә алам.

"__"________________ _____ ел ____________________

(имза)

2 нче кушымта
Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентына

Түбәндәге адрес буенча урнашкан торак бинаның халәтен тикшерү (бинаны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану)
акты № ____________
адрес ______________________________________________________________

__________________________ "___"____________ ____ ел
(торак пункт) (дата)

Ведомствоара комиссия, билгеләнгән ________________________________
___________________________________________________________________________
(башкарма хакимият федераль органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы исеме)
"___"____________ ____ ел N __________________карары белән, түбәндәге составта
рәис _____________________________________________________
(Ф.И.О.,били торган вазыйфа һәм эш урыны) һәм комиссия әгъзалары:
_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)
чакырылган экспертлар катнашында ____________________________________
_________________________________________________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)
һәм чакырылган бина милекчесе (яки: вәкаләтле зат)
_________________________________________________
(Ф.И.О., паспорт мәгълүматлары һәм эш урыны),

гариза буенча бинаны тикшерүне уздырды
________________________________________________________
(гариза бирүченең реквизитлары: Ф.И.О. һәм адрес – физик зат өчен, оешма исеме һәм били торган вазыйфа – юридик зат өчен) һәм әлеге актны төзеде.
бинаны тикшерү ___________________________________________________
(адрес, бинаның билгеләнеше, кадастр номеры, кулланылышка тапшыру елы).
Торак бинаның, бинаның инженер системаларының, җиһазларның һәм бинага чиктәш территориянең халәтенә кыскача тасвирлама: ______________
___________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

Куелган таләпләргә туры килмәү турында мәгълүматлар, күрсәткечләрнең фактлагы күрсәтмәләрен яки конкрет туры килмәүне күрсәтеп ___________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

Уздырылган инструменталь контроль һәм башка контроль һәм тикшерү төрләре нәтиҗәләренә бәя бирү________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_______________________________________________________ (контроль (сынау) кем тарафыннан, нинди күрсәткечләр буенча уздырылган, фактта нинди күрсәткечләр алынган).

Ведомствоара комиссия рекомендацияләре һәм иминлекне тәэмин итү өчен кабул итәргә кирәкле тәкъдим ителгән чаралар яки даими рәвештә тору өчен гадәти шартлар булдыру

__________________________________________
______________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________.

Бинаны тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе:

1. _________________________________ адрес буенча торак бинаны таныргa _____________________________________________________________________ яшәү өчен яраклы (яки: яраксыз) дип таныргa;

2. ____________________________________________________________________;

3. ____________________________________________________________________.

Актка беркетелгән:

1) инструменталь контроль нәтиҗәләре;
2) лаборатор сынаулар нәтиҗәләре;
3) тикшеренүләр нәтиҗәләре;
4) проект-тикшерү һәм махсуслаштырылган оешмаларның экспертлары бәяләмәләре;
5) ведомствоара комиссия карары буенча башка материаллар.

Ведомствоара комиссия рәисе

__________________________ ___________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

__________________________ ___________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

__________________________ ___________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

__________________________ ___________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

3 нче кушымта
Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентына

(форма)

Бинаның (күпфатирлы йортның) бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак бина дип һәм торак бинаны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүенә бәя бирү турында

**БӘЯЛӘМӘ**

№ ______________________________ ________________________________
(дата)

___________________________________________________________________
(месторасположение помещения, в том числе наименования населенного пункта и улицы, номера дома и квартиры)

Ведомствоара комиссия, билгеләнгән __________________________________
(кем тарафыннан билгеләнгән, башкарма хакимият

___________________________________________________________________
федераль органы, Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органы исеме, комиссия чакыру турында карар номеры һәм датасы)
составында, рәис ____________________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)

___________________________________________________________________

һәм комиссия әгъзалары __________________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)
чакырылган экспертлар катнашында _________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)

___________________________________________________________________

һәм чакырылган бина милекчесе яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат катнашында

______________________________________________________________________________
(Ф.И.О., били торган вазыйфа һәм эш урыны)

каралган документлар нәтиҗәләре буенча ______________________________________

(документлар исемлеге китерелә)

______________________________________________________________________________

һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән ведомствоара комиссия акты нигезендә,

______________________________________________________________________________

(тикшерү актыннан алынган бәяләмә китерелә (тикшерү уздырылган очракта), яки ведомствоара комиссия

______________________________________________________________________________

карары нигезендә тикшерү уздырылмаганлыгы күрсәтелә)

______________________________________________________________________________

________________________________________ турында карар кабул итте

(бинаның (күпфатирлы йортның) бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм

______________________________________________________________________________

күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле

______________________________________________________________________________

дип тану турында Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүенә бәя бирү турында ведомствоара

______________________________________________________________________________.

комиссия тарафыннан кабул ителгән бәяләмәгә нигез китерелә)

Бәяләмәгә кушымта:

а) каралган документлар исемлеге;

б) бинаны тикшерү акты (тикшерү уздырган очракта);

в) ведомствоара комиссия тарафыннан соратылган башка материаллар исемлеге;

г) ведомствоара комиссия әгъзаларының аерым фикерләре:

Ведомствоара комиссия рәисе

| ____________________ | ________________________________ |
|---|---|
| (имза) | (Ф.И.О.) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| ____________________ | ________________________________ |
|---|---|
| (имза) | (Ф.И.О.) |
| ____________________ | ________________________________ |
| (имза) | (Ф.И.О.) |

4 нче кушымта
Бинаны торак урыны, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Админстратив регламентына

Татарстан Республикасы
______________муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
__________________________нан

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________________________

(хезмәт күрсәтү исеме)

Язылган:____________________________________________________________

_____________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:___________________________________________________________

____________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.

2.

3.

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны җибәрүегезне сорыйм:

электрон документны җибәрү адресы E-mail:________________________;

расланган күчермә рәвешендә кәгазьдә почта аша түбәндәге адрес буенча: _________________________________________________________________.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), куллану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокадалау, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле бүтән гамәлләр кабул итүне дә кертеп) үз ризалыгымны, мин тәкъдим итә торган затның ризалыгын раслыйм, шул исәптән автоматлаштыру режимында, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан карарлар кабул итүне дә кертеп.

Раслыйм: гаризага кертелгән минем шәхесемә һәм мин тәкъдим иткән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага кушып бирелгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм анда дөрес мәгълүматлар кертелгән.

Телефон аша бирелгән муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча сораштыруда катнашырга үземнең ризалыгымны бирәм: ________________________.
______________ _________________ ( ________________)

(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аны башкаруны контрольдә тотуны тормышка ашыручы вазыйфа затларның реквизитлары**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **8(843)2-30-51** | Lyuciya.galiulina @tatar.ru |
| Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче | **8(843)2-30-63** | Sabirova.guzel @tatar.ru |
| Бүлек начальнигы | **8(843)2-30-68** | Ramil.Hakimullin@tatar.ru |
| Бүлек белгече | | Fatyhov.Denis @tatar.ru |

**Биектау муниципаль районы Советы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башлык | **8(843)2-30-60** | biektau @tatar.ru |